ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**КАРАР**

**№ 17** **Бәйрәкәтамак ав.** **15.11.2022**

**Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 мартындагы "Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы 4 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 маддәсе, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2010 елның 19 августындагы ЯК-7-8/393 санлы боерыгының 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 мартындагы 4 санлы карарына (2021 елның 1 июнендәге 5 санлы, 2021 елның 20 августындагы 9 санлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 пунктта:

Түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"- физик затларның җир салымы һәм мөлкәтенә салым, балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче ата-ана хокукыннан мәхрүм калган балигъ булмаганнарга карата пенялар һәм штрафлар буенча;

- җир салымы буенча ЕВРЮЛда мәгълүмат булмаган юридик затларга карата;

- юридик затларның пенялар буенча бурычлары, бурычка түләтелгәннән соң, аны түләттерү срогы чыкканнан соң түләтелгән бурычлары булу, аларга исәпләнгән недоимка булмаганда».

2. Әлеге карар үзенең гамәлен бурыч барлыкка килгәннән бирле барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, hpps://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтындагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы: Ф.В.Әхмәтов